КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 26 март г.Казань № 173

«Агросәнәгать комплексын кадрлар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2017 ел, 21 ноябрь, 893 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

«Агросәнәгать комплексын кадрлар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2017 ел, 21 ноябрь, 893 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 8 апрель, 235 нче карары белән расланган «2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында әлеге максатлар өчен Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына каралган акча исәбеннән агросәнәгать комплексы җитәкчеләренә һәм белгечләренә конкурс нигезендә бирелә торган грантларның гамәлгә куючысы булырга.»

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексының иң яхшы хезмәткәрләренә премияләр түләү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан акча бирү тәртибендә:

1.4 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Премияләр бирү бу Тәртипнең 1.1 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында күздә тотылган бюджет ассигнованиеләре һәм Министрлыкка бюджет акчасын алучы буларак билгеләнгән тәртиптә ирештерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексын кадрлар белән тәэмин итүгә дәүләт ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан акча бирү тәртибендә:

2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Акча бирү бу Тәртипнең 1.1 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында күздә тотылган бюджет ассигнованиеләре һәм Татарстан Республикасының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлыкка) бюджет акчасын алучы буларак билгеләнгән тәртиптә ирештерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин